ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 1; 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 2 өлештә:
беренче абзацта «барлык гамәлдәге» сүзләрен төшереп калдырырга;
икенче абзацта «электрон рәвештә (машинада укыла торган саклагычларда)» сүзләрен «муниципаль норматив хокукый актларның федераль регистры программа чараларыннан файдаланып электрон рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;
б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Муниципаль регистрга кертү өчен муниципаль норматив хокукый акт кергән көннән алып 10 эш көне эчендә вәкаләтле орган муниципаль хокукый актның муниципаль регистрга кертелергә тиеш булу-булмавын билгели, шул исәптән андагы нигезләмәләрнең нормативлыгына бәяләү үткәрә.»;
в) түбәндәге эчтәлекле 7, 8 өлешләр өстәргә:
«7. Муниципаль регистрга кертелергә тиешле муниципаль хокукый актлар һәм алар турындагы белешмәләр әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән срок чыккан көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча муниципаль регистрга кертеләләр.
8. Муниципаль норматив хокукый актлар турында әлеге Законның 4 статьясындагы 2 өлешенең икенче абзацы һәм 3 өлеше нигезендә бирелгән

белешмәләр муниципаль регистрга вәкаләтле органга кергән көннән алып биш эш көне эчендә кертеләләр.»;

2) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Муниципаль регистрга кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны, шулай ук алар турындагы белешмәләрне тапшыру**

1. Муниципаль норматив хокукый актлар алар кабул ителгән (бастырып чыгарылган) көннән алып 10 эш көне эчендә муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан вәкаләтле органга җибәрелә.

2. Муниципаль норматив хокукый актлар белән бер үк вакытта муниципаль берәмлек башлыгы кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актларның рәсми басылып чыгу (халыкка игълан итү) чыганаклары һәм даталары турындагы белешмәләрне дә җибәрә.

Муниципаль норматив хокукый актлар әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән сроклар чыкканнан соң рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) очракта, рәсми басылып чыгу (халыкка игълан ителү) чыганаклары һәм даталары турындагы белешмәләр, алар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан вәкаләтле органга җибәрелә.

Муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтле орган соравы буенча 15 көн эчендә муниципаль норматив хокукый актларның рәсми басылып чыгу чыганаклары булып торучы басма чаралардагы үзе раслаган күчермәләрен вәкаләтле органга җибәрә.

3. Өстәмә белешмәләр (әлеге Законның $4^1$ статьясында каралган юридик экспертиза нәтиҗәләре турындагы белешмәләрдән тыш) җирле үзидарә органнары, җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан, алар кергән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органга җибәрелә.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук алар турындагы әлеге статьяның 2 һәм 3 өлешләрендә каралган белешмәләр, Татарстан Республикасында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә эшләүче ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасының элемтә каналлары аша җибәрелә. Әлеге элемтә каналларыннан техник яктан файдалану мөмкинлеге булмаган очракта, муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турындагы белешмәләр, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган хат белән берлектә, вәкаләтле органның электрон почта рәсми адресына җибәрелергә яисә машинада укыла торган саклагычта тапшырылырга мөмкин.

5. Муниципаль регистрга кертелергә тиешле белешмәләрнең (әлеге Законның $4^1$ статьясында каралган юридик экспертиза нәтиҗәләре турындагы белешмәләрдән тыш) тулылыгын һәм дөреслеген җирле үзидарә органнары тәэмин итә.»;

3) $4^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4[1] статья. **Муниципаль норматив хокукый актларга юридик экспертиза үткәрү**

1. Вәкаләтле орган муниципаль регистрны оештырганда һәм алып барганда муниципаль норматив хокукый актларның Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына туры килү-килмәвенә юридик экспертиза үткәрә.

Юридик экспертиза үткәрү һәм аның нәтиҗәләре турындагы белешмәләрне муниципаль регистрга кертү муниципаль норматив хокукый актны муниципаль регистрга керткән датадан алып 45 көннән дә соңга калмыйча үткәрелә. Кирәк булганда, әлеге срок 15 көннән дә артыграк булмаган вакытка озайтылырга мөмкин.

2. Муниципаль норматив хокукый актта Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына каршы килә торган нигезләмәләр барлыгы ачыкланганда, юридик экспертиза нәтиҗәләре буенча төзелгән эксперт бәяләмәсе, аны төзегән көннән алып җиде эш көне эчендә, мондый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органына (җирле үзидарәнең вазыйфаи затына), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм прокуратура органнарына җибәрелә.

3. Юридик экспертиза нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив хокукый акт Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына туры килә дип билгеләнгән очракта, эксперт бәяләмәсе язмача рәсмиләштерелми, муниципаль регистрга муниципаль норматив хокукый актның федераль законнарга, Россия Федерациясе субъекты законнарына һәм муниципаль берәмлек уставына туры килүе турындагы язма теркәлә.»;

4) 5 статьяның 2 өлешендәге җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик экспертиза нәтиҗәләре турындагы белешмәләр – муниципаль норматив хокукый актның федераль законнарга, Россия Федерациясе субъекты законнарына һәм муниципаль берәмлек уставына туры килүе (туры килмәве) турындагы белешмәләр, шулай ук вәкаләтле органның юридик экспертиза нәтиҗәләре буенча төзелгән эксперт бәяләмәсе;»;

5) 6 статьяның 2 өлешендәге сигезенче абзацында «муниципаль норматив хокукый актка» сүзләрен «муниципаль норматив хокукый акт турында» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 13 июль
№ 54-ТРЗ